**«Татарстан республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2020 ел 9 ноябрь** **№ 2**

Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлегенең Акбаш авылында 2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Акбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

**К А Р А Р И Т Т Е:**

1. 2020 елның 21 ноябрендә 11.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Акбаш торак пункты, Мәктәп ур., 17 йорт адресы буенча урнашкан Акбаш авыл мәдәният йорты бинасы янында 2021 нче елда Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештырырга.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенә керүче Акбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигълык яшенә җиткән гражданнардан 2021 елда 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга сез ризамы:

1) Акбаш торак пункты Мәктәп урамы буенча асфальт юл түшәү;

2) Акбаш торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү *(төзелеш материаллары һәм җиһазлар сатып алу; эскәмияләр сатып алу һәм урнаштыру; буяу; юл җәю; пьедесталны ремонтлау;* килешү буенча эшләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», www.yutaza.tatar.ru веб-адресы буенча Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге башлыгы Л.Р. Синагатуллина